МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИРҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

15.01.2024 Казан ш. № 14-р

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында” 28.11.2023 № 3366-р карары белән расланган 2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә үзгәреш кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясына, “Оешмалар милкенә салым турында” 2003 елның 28 ноябрендәге № 49-ЗРТ Татарстан Республикасы Законының $1^1$ статьясына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» 22.08.2007 № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турындагы нигезләмәнең 3.3.101 пунктына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Россия Федерациясе Салым кодексының $378^2$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибен раслау турында” 2014 елның 21 ноябрендәге №

896 карары белән расланган Россия Федерациясе Салым кодексының 378$^{2}$ статьясының 1 пунктындагы 1 подпунктында күрсәтелгән, үзләренә карата салым базасы кадастр бәясе буларак билгеләнелә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә кертелергә һәм электрон рәвештә салым органнарына җибәрелергә тиешле мәгълүматлар составын һәм әлеге исемлекне формалаштыру, алып бару, раслау һәм бастырып чыгару тәртибенең 6 пунктына нигезләнеп:

1. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының “2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлеген раслау турында” 28.11.2023 № 3366-р карары белән расланган 2024 елга аларга мөнәсәбәтле салым базасы кадастр бәясе кебек билгеләнә торган күчемсез милек объектлары исемлегенә 453 пунктны төшереп калдырып үзгәреш кертергә.

2. Үзгәрешләр исәпкә алынган Исемлекне тиешле тәртиптә Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсенә җибәрергә.

3. Исемлекне Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының рәсми сайтында https://mzio.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның көче 2024 елның 1 гыйнварыннан соң барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагылуын билгеләргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры урынбасары А.А.Кыямовка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**